Республика Татарстан
Совет Альметьевского сельского поселения Сармановского муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге советы

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

05 октябрь 2016 ел. № 16

Әлмәт авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п., Әлмәт авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә, Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Советының 2016 елның28 сентябрендәге 15 карары нигезендә № » референдум үткәрү инициативасы турында " Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Советы карар итте:

2016 елның 19 ноябренә Әлмәт авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"2017 елда Әлмәт авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән, I төркем инвалидларыннан, көндезге уку йортларының студентларыннан тыш, 200 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

1). Җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру.
2). Җирлек территориясендә физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спорт үсеше өчен шартлар булдыру, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру.
3). Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктырту, территорияне яшелләндерүне дә кертеп).
4). Җирләү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру.
5). Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызуны оештыру.
6). Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген оештыру..

ӘЙЕ ЮК ".

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән 5 көн эчендә халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге
Советы Рәисе Д.Ә. Газизов.